**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

2017 ел, 12 май

№ 276

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарын һәм социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр күрсәтә торган социаль хезмәтләрне финанслауның җан башына нормативларын хисаплап чыгару тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2009 ел, 31 декабрь, 915 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарын һәм социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр күрсәтә торган социаль хезмәтләрне финанслауның җан башына нормативларын хисаплап чыгару тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарын һәм социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр күрсәтә торган социаль хезмәтләрне финанслауның җан башына нормативларын хисаплап чыгару тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2009 ел, 31 декабрь, 915 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 30 декабрь, 1097 нче; 2014 ел, 31 декабрь, 1096 нчы; 2015 ел, 6 май, 325 нче; 2015 ел, 12 ноябрь, 847 нче; 2016 ел, 1 март, 127 нче; 2016 ел, 4 июнь, 372 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарын һәм социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр күрсәтә торган

социаль хезмәтләрне финанслауның җан башына нормативларын хисаплап чыгару тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 бүлекнең 1.9 пунктындагы дүртенче абзацта «яшәүченең айга, көнгә бер хезмәт күрсәтү» сүзләрен «яшәүченең елга» сүзләренә алмаштырырга;

1 бүлекнең 8 таблицасындагы 4 графада:

«Акылы зәгыйфь балалар өчен балалар интернат йорты» һәм «Физик кимчелекләре булган балалар өчен балалар интернат йорты» юлларында «0,349» саннарын «0,383» саннарына алмаштырырга;

3 бүлекнең 3.2.1 пунктчасындагы бишенче абзацта «3.1.1» саннарын «4.1.9» саннарына алмаштырырга.

2. Бу карарның гамәле 2017 елның 1 мартыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тарала дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\276.docx